*Әңгәмәдәшебез — Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтов. М.И.Мәхмүтов 1926 елда туган. 1958-76 елларда Татарстан мәгариф министры булып эшли. Ул - филология фәннәре кандидаты, педагогия фәннәре докторы. 70-90 елларда ул СССР Педагогия фәннәре академиясенең һөнәри педагогика фәнни-тикшеренү институтын оештыра һәм 17 ел җитәкли. 1992 елда Татар-Америка төбәк колледжына нигез сала. Татарстан Фәннәр академиясе академигы буларак нәтиҗәле гыйльми эш алып бара.*

# Мирза Мәхмүтов:

# Әхлакның нигезе - матди бөтенлек!!!

**- Мирза Исмәгыйлович**. **Сез Татарстаннан читтә туып та, гомер буе Татарстанга һәм татар халкына хезмәт иттегез. Нәкъ менә шушы тормыш һәм яшәеш юлын сайлавыгызганиләр йогынты ясады?**

- Чынлап та, Татарстанга мине урау юллар китерде. Әнием - Сембернеке, әтием - Мордовиядән, "пинзә мишәре". Алар бәхет эзләп килгән җирләреннән Баку шәһәрендә очрашып кавышканнар. Мин дә шунда дөньяга килгәнмен. Җидееллык мәктәпне һәм тракторчылар курсын тәмамлаганнан соң, Сәмәрканд өлкәсендә ике ел механизатор булып эшләдем. Сугыш вакытында армиягә киттем, фронт исен дә иснәргә туры килде. Армиядә барлыгы унике ел хезмәт иттем. Армия миңа шактый белем дә бирде. Авиация техникгы һөнәре үзләштердем, чит телләр хәрби институтында белем алдым. Шул белемем белән Балтыйк буе хәрби округында тәрҗемәче булып эшләдем.

Бабам Гайнетдин, "Татар теле - яхшы тел" дип җырларга яраткан әнием Зәйнәп минем күңелемә кече яшьтән үк милли моң сеңдергәннәрен аңлады-лармы-юкмы икән, белмим. Ләкин мине гел Татарстан үзенә тарта иде. Механизатор һәм техник һөнәрем булганлыктан, Россия авыл хуҗалыгы министрлыгына юллама сорап кергән идем, Татарстанда МТС директорлары кирәк, диделәр. Ә инде Казандагы министрлыкта вакансия көтеп утырганда профессор Хатип Госман килеп чыкты. "Шушындый белем белән Сез МТСка китәргә җыенасыз. Университетта бер генә гарәп теле белгечебез дә юк бит. Килегез", - диде. Риза

булмадым. Хатип ага белән кабат очрашырга туры килде. Бу юлы ул мине университет ректоры М.Т.Нужин янына ук алып китте. Бераз сөйләшеп утырганнан соң, ректор миңа аспирантурага керергә тәкъдим ясады. Аспирантура - белем алу дигән сүз. Мин ризалашмый булдыра алмадым. Шулай итеп, берьюлы фән белән дә шөгыльләнә, студентларга гарәп теле дә укыта башладым. 1956 ел иде бу.

- **Шуннан соң озак та узмый Сез Татарстанның мәгариф министры итеп билгеләнгәнсез. Билгеле булганча, бу чор, илленче еллар азагы, мәгариф реформасы, шул исәптән татар милли мәгарифенең яңа бер сулыш ала башлаган вакыты. Сезнең министр булып билгеләнүегез шуның белән бәйле идеме?**

- Сугыштан соңгы елларда мәктәпләрнең, бигрәк тә татар мәктәпләренең хәле бик мөшкелләнгән иде. Илленче елларда мәгарифне реформалаштыру зарурлыгы хакында фикерләр ишетелә башлады. Моңа мин дә битараф түгел идем. Күпләр як-ягына карап кына сөйләгәндә, мин Үзәк Комитет кешеләре алдында шактый гына кыю чыгышлар ясадым. Читтән килгән кеше буларак, бик куркып тормадым. Мәскәүдән килгән махсус комиссия алдында дүрт-биш мәртәбә чыгыш ясап, татар телен саклап калу турында гына түгел, безгә гарәп телен дә кайтарырга кирәк, дип сөйләгән идем.

Бераздан, 1958 елның маенда, шушы мәсьәләләргә багышлап КПСС Өлкә комитетының махсус пленумы узды. Мәгариф министры Әминә Вәлиуллинаны шактый гына тәнкыйтьләделәр, эшеннән алдылар. Мине исә, өлкә комитетына чакырып, мәгариф министрлыгын җитәкләргә тәкъдим ясадылар. Янәсе, бик оста тәнкыйтьләдең, инде үзең эшләп күрсәт.

- **Сәбәп бу гына булмагандыр инде.**

- Өлкә комитетның ул чактагы бүлек мөдире Фикърәт Табеев белән без университетта, нык ук аралашмасак та, күрешеп-сөйләшеп йөри идек. Ул, күрәсең, минем җәмәгать эшләрендәге активлыгыма игътибар иткән: халыкара хәлләр буенча лекцияләр укый идем, профкомда эшчәнлек алып бардым. Мин гуманитар хәрби вузда белем алган, университетта татар теле кафедрасы мөгаллимнәре, татар зыялылары белән аралашам, язучылар берлегендә һәм университетта гарәп теле укытам, "Гарәпчә-татарча-русча алынмалар" сүзлеген эшләп бетереп барам. Табеев мине яңа эшкә тәкъдим иткәндә бу яктан да мөмкинлекләремне исәпкә алгандыр, мөгаен.

- **Димәк, аның күңелендә дә милли хисләр булган?**

- Әйе, миллилек бар иде аның күңелендә. Бар иде. Ул да чыгышы белән Татарстаннан түгел бит. Читтәге татарларда Казан татарларына караганда миллилек көчлерәк була. Чөнки алар чит милләт мохитендә яши. Мондагы татарлар, үз мохитендә яшәгәч, кирәк-кирәкмәс
чакта бер-берсен чиртеп тә алгалыйлар. Ә Фикърәт Табеев соңрак: "Син татар мәктәбен торгызуда курыкмыйча эшлә, кирәк икән ярдәм итәрмен, ярамаса әйтермен", - ди иде.

Өлкә комитетның ул вакыттагы беренче секретаре Семен Денисович Игнатьев, секретарьлар Салих Батыев, Камил Фасеевка: "Педагогик белемем юк, мәктәптә эшләп карамадым. Ничек инде миңа шундый җаваплы эш тәкъдим итәсез?" - дип карышып карадым. Игнатьев бер генә сүз әйтте: "Өйрәтербез!". Тыңламый кара. Ул бит беренче секретарь. Аннан мин Игнатьевның каян килгәнен дә белә идем. Заманында союз КГБсын җитәкләгән кеше бит ул. Менә шулай итеп яңа эшкә керештем. Министр булып 1958 елдан башлап, барлыгы 18 ел эшләдем.

**- Мирза Исмәгыйлович, яңадан әнә шул илленче еллар азагына әйләнеп кайтсак, шул чорда мәгариф өлкәсендә башланган күп кенә реформалар туктап калган, милли мәгариф үсеше алтмышынчы елларда әкренләп сүрелгән. Моның сәбәбе нидә?**

- Мин килгән чорда мәгариф өлкәсендә милли рух күтәрелү юлында иде. Бу инде Никита Хрущев заманасы ирекләре, "җепшеклек" чоры белән дә бәйле булгандыр. Ләкин бераздан Өлкә комитеты пленумының татар мәгарифен үстерүгә юнәлдерелгән карарын, Үзәк Комитет сүзенә буйсынып, тавышсыз-тын-сыз гына юкка чыгардылар. Мәскәүдә яшәгән безнең кешеләр үк безне милләтчелектә гаепләп шикаятьләр оештыра башлаганнар икән.

Аның башка сәбәпләре дә булды. Бөек Ватан сугышыннан соң рус халкының милли үзаңы уяна башлады. Хәтерем ялгышмаса, 1962 елда бугай, Никита Хрущев Украинага бара һәм анда аңа генераллар болай ди: "Армиягә килгән яшьләрне техникага утырта алмыйбыз: алар рус телен белми". Хрущев әйтә: "Нигә кирәк украин теле? Русча гына укытыгыз". Партократ-идеологларга шул җитә калды. Мондый "күрсәтмә" бер генә булмый. Кольск ярымутравына баргач та Хрущев шундыйрак вәзгыятькә тап була. Аңа: "Менә безнең төньяк халыклары өчен ана телләрендә укыта торган мәктәпләребез бар", - дип мактаналар. Хрущевның моңа бик нык ачуы килә. Шуны гына көтеп торган Россия Мәгариф министрлыгы вак милләтләрнең телен кыса башлады. Җидееллык милли мәктәпләрне дүртьел-лыкларга, дүртьелыкларны берьеллыкларга калдыра башладылар. Кавказ

халыклары өчен исә әзерлек класслары гына калды.

Безне, "автономияләр министрларын", төрле киңәшмәләргә җыеп, әлеге сәясәтне ныклап үткәрә башладылар. Мин шул киңәшмәләрдә, русча укыту белән беррәттән, татар мәктәбен саклап калырга кирәклеге турында да сөйли, мәгарифебезнең бай тарихы булуы, бүгенге потенциалы хакында әйтә идем. Башка милләтләр министрлары соңыннан яныма килеп кулымны кыса иделәр. Ә Россиянең ул чактагы министры Е.И.Афанасенко мине үз кабинетында ялгыз гына калдырып: "Инде Сез үзегезчә эшләсәгез дә, трибунадан алай сөйләмәгез, һич югы минем үземә әйтегез", - ди торган иде. Кыскасы, татар мәктәбен урта белем дәрәҗәсендә саклап калу өчен тартышу, көрәшү шактый еллар барды.

Бервакыт мәгариф әһелләрен Уфага җыйдылар. Мәскәүдән министр урынбасары М.И.Кашин килгән иде. Татар һәм башкорт мәктәпләрен унъеллыктан сигезел-лыкка калдыру турында карар проекты да әзерләнгән. Чөнки башка вак милләтләргә: "Нигә сез милли мәктәпне дүртьеллыкка калдырмыйсыз?", - дигәч, алар: "Әнә бит татарлар белән башкортларның унъеллык мәктәпләре бар", - дип җавап бирәләр икән. Кыскасы, без башка вак милләтләрне кысарга ирек бирмибез булып чыкты. Сизәм, хәл начар. Башкортстан министры Фатыйма Мостафина белән утырып сөйләшәбез. Бу мәсьәлә буенча төп докладны ул ясарга тиеш иде. Мин әйтәм: "Сакларга кирәк милли мәктәпне. Әйдәгез, яклап чыгыйк". Ул: "Кирәген кирәк тә, менә Өлкә комитетында киресенчә чыгыш ясар га куштылар", - ди. Шуннан нишләргә? Мостай Кәримне эзләп таптым, мин аның белән таныш идем. Хәлне аңлатып бирдем. Абруйлы шагыйрьнең сүзен дә трибунадан әйттерәсем килгән иде. Килештек. Шулай итеп, башта Фатыйма ханымның чыгышын тәнкыйтьләп мин сөйләдем. Халыкның фикере өйрәнелмәвенә басым ясадым. Миннән соң Мостай Кәрим сөйләде. "Милли мәктәпләр бетсә, кем өчен язарбыз?" - дигән сүзләре хәтеремдә. Нәтиҗәдә бу юлы татар һәм башкортның урта мәктәбен саклап кала алдык.

- **Бүген милли мәгарифнең үсешенә мондый куркыныч янамый инде...**

- Уяу булыйк: икенче төрле куркыныч яный. Россиядә татарларның 49 проценты гына туган телен белә, 69 проценты аны үзенең ана теле дип саный. 1959 елда бу күрсәткеч 87 процент иде. Киләчәктә сан үзгәрешләренең кайсы якка тәгәрәве аңлашыла. Нишләргә? Алфавитны алмаштырырга кирәк, диләр. Хәреф алыштырып кына милләт исән кала алырмы икән?! Инглизләр сигез хәреф белән ике генә аваз белдерәләр, ләкин реформа ясамыйлар бит. Графика белән бергә орфография дә үзгәрәчәк. Бөтен халыкны яңадан

укырга-язарга өйрәтергә тиеш булабыз. Халыкны тагын, өченче мәртәбә ярымнаданга әйләндерәчәкбез.

Безгә азәрбайҗаннар мисалын күрсәтәләр. Имеш, алар җиңел генә күчеп яталар. Без татарларны алар белән чагыштырырга ярыймы соң? Алар бит мөстәкыйль дәүләттә яшиләр; милләтләре бер җирдә тупланып урнашкан, безнең кебек сибелмәгән. Ә без, "тотса мәскәү-ләр якаңнан", нишләрбез? Башкортс-танда гына күпме милләттәшебез яши, ә анда хәреф алыштырырга җыенмыйлар. "Татарлар өчен дә дәреслекләрне үзебез бастырабыз", -диләр. Безнең графика алыштырудан файдаланып, аларның нинди сәясәт үткәрергә җыенганын чамалыйсыздыр, шәт?

Адәм баласы табигый рәвештә хәбәр эзли, информацияне мөмкин кадәр җайлырак юл белән алырга тырыша. Латинны кайтарсак, күпчелек татар кешесе өчен кириллица мәгълүмат үзләштерү өчен җайлырак графика булып калачак. Монда хәреф тану түгел, күнегүнең булу-булмавы әһәмиятлерәк. Димәк, алар русча укуга күчәчәк. Татар әдәбиятын, матбугатын укучылар саны, шиксез, кискен кимиячәк.

1998 елда бер мәкаләмдә латин графикасын күтәреп чыгып кирәкмәгән эш белән шөгыльләнүчеләрне тәнкыйтьләгән идем. Колак салучылар булмады бугай. Имештер, бүген латинны кайтару юнәлешендәге эксперимент уңай нәтиҗәләр биргән. Уңайдыр. Баланы иероглифка да, әллә нинди хәрефләргә дә өйрәтеп була анысы. Ләкин 'буыннар чылбыры өзелү" куркынычы турында уйланучылар күренми шикелле. Инде бо-лай да әллә ничә җирдән өздек, борынгы язу культурасы булган милләттән "младописьменный народ" булып калдык.

"Язу культурасы" бар, "язма культура" дигән төшенчә бар. Мәгънәләре бер үк түгел шул. Язу культурасына, ягъни дөрес һәм матур язуга бик тиз өйрәнеп була. Ә язма культура - ул безнең мең еллык тарихыбыз, сәнгатебез, мәгарифебез, китапчылыгыбыз. Графика алмаштыру әнә шул язма культурага, халыкның мәдәниятенә, аның менталитетына зур зыян сала.

- **Мирза Исмәгыйлович, Сез җитәкчелек иткән чор мәгарифенә әйләнеп кайтсак, бүгенге көн күзлегеннән аңа нинди бәя бирер идегез? Ул заман мәгарифенең кайсы кыйммәтләрен безнең бүгенгебез өчен аеруча мөһим дип санызсыз?**

- Мәгариф системасы - теләсә кайсы илдә консерватив система. Аның дәреслеге языла да, балалар шуның белән әллә ничә еллар буе укый. Укытучыны теге яки бу фәнне укытырга бер тапкыр өйрәтәләр дә, ул шулай итеп гомер буе

укыта. Бу
система көн саен, ел саен алмашынып торырга әзер түгел. Һәм бу дөрес тә: мәгариф - җәмгыятьнең нигезе. Горбачевлар заманыннан башлап икътисад сүтелде, сәясәт җимерелде, идеология юкка чыкты, ә мәгариф сакланып калды.
Җәмгыятьнең сәяси системасы алмашынды, ә мәгариф системасы аз үзгәрде.

Хәзер тормыш бик тиз үзгәрә, яшәү, эш шартлары үзгәрә, производствога яңа технологияләр керә. Ә мәгариф һәрчак арттарак кала һәм аны даими үзгәртеп тору ихтыяҗы бар. Шуңа да һәрбер илдә 25-30 ел саен мәгариф системасына реформа ясыйлар. Илленче еллар азагында мәктәп системасына реформа ясый башлау - бик табигый хәл. Аңа кадәр без гимназистик системага ябышып ята идек. Белем бирәбез, ә хезмәткә һәм тормышка тиешенчә әзерләмибез. 1958 елда "Мәктәпне тормыш һәм хезмәт белән бәйлибез" дигән тезис нигезендә реформа башланды. Производствога өйрәтү цехлары төзү, мәктәпләрне заводларга беркетү аша балаларга хезмәт тәрбиясе бирә башладык.

Ләкин Мәскәү үзенә күрә дәүләт эчендә дәүләт бит ул. Безнең балалар эшче яшьләр белән аралашып, шул тормышның кыйммәтләрен үзләштерә башлагач, Мәскәүдәге кайбер түрәләр: "Ничек инде минем улым-кызым токарь-мокарьлар белән аралашып йөри", - дип бу реформаның нигезенә ачуланып аяк чала башладылар. Астыртын гына реформаны туктату юнәлешендә эш башладылар. Хрущев киткәч исә тәмам бетерә яздылар. Производство мәктәпләрен ябарга, завод-фабрикалар белән элемтәне өзәргә, дәреслекләрнең эчтәлеген алмаштырырга керештеләр.

Шулай итеп, башланган игелекле эшкә киртә куелды. Яңа мәктәп биналары төзү, яңа дәреслекләр чыгару, укытучылар белемен күтәрү, мәгарифне финанслау Хрущев заманында бик яхшырган иде. "Мүкләнеп яткан" мәктәп системасы урыныннан кузгалып китте, күтәрелә башлады. Моның өчен Никита Сергеевичка рәхмәтле булырга тиешбез. Бүген дә мәгарифкә мөнәсәбәт шундый булсын иде ул. Аны җәмәгать тәртибендә генә, ачлы-туклы укытучы җилкәсенә салып кына күтәреп булмый.

**- Яңа институт оештыру заманында Сез җитәкләгән фәнни-тикшеренү институты эзләнүләренең практик нәтиҗәсе дә булгандыр инде?**

- Әйе, институт галимнәре язган теория һәм методикаларга нигезләнеп, илнең һөнәри мәгарифе системасына яңа программалар, яңа дәреслекләр килде. Үзем дә, һөнәри белем бирүнең теориясен үзләштергән кеше буларак,

шуны практикада, яңа шартларда сыный алдым.

- **Сезнең фәнни эшчәнлегегез күптармаклы. Бүген дә бик популяр булган "Гарәпчә-татарча-русча" сүзлегегез татар теленең тарихи лексикасын саклап калуда зур роль уйнады. Халкыбызга Ислам әдәбиятын җиткерүдә өлешегез зур. Эзләнүләрегезнең тагын бер җитди тармагы булган проблемалы укыту турында заманында бөтен ил шаулаган иде. Бу алым бүгенге мәгариф өчен дә актуальме?**

- Моны мин педагогика фәненә керткән иң зур өлешем, дип саныйм. Педагогиканың нигезендә дидактика ята. Укучыны "нәрсәгә" һәм "ничек" өйрәтергә дигән сорауга җавап бирүче фән ул. "Ничек" өйрәтергә дигән сорау аеруча мөһим. Бер үк дәреслек белән эшләүче ике укытучы фәнне ике төрле укытырга мөмкин. Берсенең эш нәтиҗәләре менә дигән, икенчесенең укучыларына дан. Мин менә шул мәсьәләне өйрәнергә керештем, алдынгы укытучыларның эш тәҗрибәсен гомумиләштердем, мәгълүм идея һәм фикерләү психологиясе нигезендә системага салдым. Шулай итеп, "проблемалы укыту" теориясе хасил булды. Аның нигезендә укучыны фикерләүгә өйрәтү ята. Кешенең фикерләү сәләте азмы-күпме тумыштан була, ләкин аңа гына өметләнеп булмый: сәләтне махсус рәвештә даими үстерергә кирәк. Кешене җырларга яисә биергә махсус өйрәткән кебек үк. Проблемалы укыту аша фикерләүгә өйрәтү тотрыклы теория булып чыкты. Аны союзда хуплап алдылар, чит илләрдә игътибар иттеләр. Ул бүген дә бик актуаль: укытучыларның бер өлеше аны уңышлы гына куллана.

**- Мирза ага, мәгарифнең киләчәктәге өстенлекле юнәлешләре нинди булыр икән? Башланып киткән яңа гасыр мәгарифен Сез ничегрәк күзаллыйсыз?**

- Хәл ителәсе өч-дүрт мөһим проблема бар бездә. Беренчесе - әдәп-әхлак тәрбиясе. Кеше нинди генә белемле булмасын, әгәр дә әхлакый ягы йомшак булса, ике аягына да аксый торган кеше була. Ялганлау, яхшыны яман, яманны яхшы дип күрсәтү, хәрәм малга кызыгу, кеше белән исәпләшмәү, ата-ана-га кырын карау, күрше-күләнне рәнҗетү, балаларны кыерсыту белән шөгыльләнгән кеше, белемле булса да, хайвани зат була ул.

Менә хәзер, элеккеге системаны сүтеп ташлагач, өскә кемнәр калкып чыкты? Белемсезләр дисезме? Юк, күбесе югары белемле. Яманлык эшлиләр, хәрәм эш белән шөгыльләнәләр, чөнки алар тәрбиясез, әхлаксыз кешеләр. Яшь буынны иманлы итү - бүгенге мәктәпнең беренче проблемасы ул.

Иртә белән эшкә барганда шундый күренешкә еш тап булам. КАИ бинасы янына

яшьләр җыелган. Япь-яшь кызлар шешә авызыннан сыра суырып, тәмәке тартып утыра. Алар-га нинди өмет булсын?! Кайсы чирләр белән генә авырмыйлар бүген?! Вуз яшьләренең бер өлеше хайвани дәрәҗәгә төшеп бара бит. Бөтен яшьләребез дә шундый, дип әйтмим. Ләкин андыйлар күп булгач, нишләргә кала инде? Кайбер мәгълүматларга караганда, Европада студентларның 30 проценты наркотик куллана икән. Ә Россиядә күпме дип беләсез? 50 процент! Наркоманнан ни көтәргә кала соң?! Гомерлек авыру бит ул. Наркоманиядән үлеп кенә котылып була.

Менә шул дәрәҗәгә килеп җиткәч, ничек әйтмисең: мәктәптә бүген беренче планда белем бирү түгел, әхлак тәрбиясе торырга тиеш. Ләкин тәрбия ана сөте белән керә. Халыкта: "Ана сөте белән кермәсә, тана сөте белән кермәс", - диләр. Телевизордан яшьләр һәр көнне шашып шәрә кызлар, порнофильмнар карый. Татар авылында ирләр генә түгел, хатын-кыз стаканлап аракы эчә. Моны күреп балалар, үсмерләр олыларча кылана. Роберт Миңнул-линның "Ник эчәсең, татар?" дигән шигыре җан әрнүеннән туган, дип уйлыйм. Бабалар ишетмәгән авырулар хасил булды, ата улны, ана кызны белмәгән хәл туды. Бу бит - ахырзаман.

Кем балаларга әхлакый тәрбия бирәчәк? Моның өчен мохитебез, тормыш рәвешебез үзгәрергә тиеш. Әдәпле, тәрбияле гаиләдә үскән кеше үзе, без өйрәтмичә дә баласына дөрес тәрбия бирә ала. Ләкин гаиләләрнең күбесе әхлаксызлык шаукымында яши. Моны сукыр кеше дә күрә. Әхлакый яктан түбән төшүебезгә минем генә йөрәгем әрнимени?!

- **Кайчан чыгарбыз соң без бу хәлдән?**

- Тиз үк булмас, дип уйлыйм. Россия бу әхлаксызлык сазлыгыннан чыкса да, 40-50 елларсыз булмас, мөгаен. Чөнки әхлаклылыкның нигезендә матди бөтенлек булырга тиеш. Икътисад хәзергә бик түбән дәрәҗәдә. Халыкның хәлен гадәттә еллык гомум милли продукт белән үлчиләр. Аны җан башына бүләләр дә, кем ничек яшәгәне күренә. 5 ел элек бездә җан башына 5700 доллар туры килә иде. Хәзер 4 меңгә төшкән. АКШта 30 мең, Германия, Англиядә 24-28 мең, хәтта Төркиядә, Мисырда 6 мең доллар булды. Азия-Африканың артта калган илләре дәрәҗәсенә төштек.

Мәгариф системасы да шулай: 50-60 нчы урыннарда торабыз. Сәләтле балаларыбыз бар анысы. Олимпиадага җибәрәсе булса, бер миллион укучы арасыннан ике-өч кеше сайлап җибәрәбез дә, алар 10-12 нче урынны яулап кайтсалар, мактанабыз, без - талантлы халык, мәгарифебез яхшы, дип сөйлибез. Мең башмак арасыннан күргәзмәгә бер матурны сайлап алып була, ләкин бөтен

башмаклар да яхшы дигән сүз түгел әле бу.

Әхлаксызлыкның төп сәбәбе хәерчелек һәм имансызлык. Халык үзенең киләчәген күрмәсә, диңгез дулкынындагы бер йомычка кебек чайкала башлый. Берәр ел хезмәт хакы алмаган укытучының рухи халәте нинди була?

Мәктәптә балага: 'Тәрбияле бул", дип әйтәбез. Ләкин мәктәптән чыгу белән аның акчасын талыйлар. Үсә төшкәч, үзе дә шулай талый башлый. Мохите шундый. Менә бүген Россиядә 2 миллион чамасы укый-яза белми торган яшьләр бар, мәктәп яшендәге балалар. Коммунистлар шулкадәр тырышып-тырмашып наданлыкны бетерде. Ә демократлар? Рәхим итегез, ирек. Ирек дигән сүзне Россиядә дөрес аңлыйлармы соң? Аны "теләсәң нәрсә эшләргә ярый" дип аңлыйлар. Әхлаксызлык-ның бер сәбәбе шул да әле.

**- Нишләргә соң, әхлаклылык дәрәҗәбезне ничек күтәрергә, Мирза Исмәгыйлович?**

- Борынгылар "Өметсез - шайтан" дигәннәр. Адәм баласы берәр нәрсәгә анырга тиеш, рухи таянычы булмаса, ул төшенкелеккә бирелә. "Якты киләчәк" килмәде...Яшәешнең мәгънәсен аңлар өчен безгә дин булышыр, дип уйлыйм мин. Корьәндә әхлак мәсьәләләре бик җентекле язылган. Кеше нәрсә эшләргә тиеш, нәрсә эшләргә ярамый. Нәрсә - хәләл, нәрсә - хәрәм. Ак белән караны, яман белән яхшыны аера белергә өйрәнмәсәк, бетәбез. Дин белән дәүләт аерым, дигән законда. Ләкин диннең бик матур тәгълиматы да бар бит әле. Дини әдәбияттан әхлаклылык турында матур сүзләрне алып, уку-укыту әсбапларына кертү һәм аларга педагогик комментарийлар бирү зарур. Бу - укытучы өчен ярдәмлек булыр иде. Балалар дингә ышанмыйлар, имеш. Ышанмасын. Ә син аңа сөйлә. Үсә төшкәч аңлар. Имансызлар диләр. Имансыз ул Аллага ышанмаган гына түгел, татарда ул әдәпсез, тәртипсез дигәнне дә аңлата. Дингә таянып, сәнгатькә, әдәбиятка, шигъриятькә таянып, гореф-гадәтләребезгә таянып, балаларны иманлы итәргә кирәк. Укытучыларның үзләрен дә шул юлга тартырга кирәк, дип уйлыйм.

**- Киләчәк мәгарифе өчен тагын кайсы проблемалар актуаль дип санныйсыз?**

- Фикерләү сәләтен үстерү, киңрәк әйткәндә – интеллектны үстерү. "Интеллект" сүзе фикерләүне дә, зиһенне дә, акылны да һәм шул акыл белән эш итүне белдерә. Бу сүз - күп телләрдә бик киң кулланыла торган термин да, төшенчә дә. ЮНЕСКО даими рәвештә төрле илләрдәге яшьләрнең

интеллектуаль потенциалын махсус коэффициент белән үлчи. 60 нчы елларда илебез бу күрсәткеч буенча Америка һәм Канададан кала өченче урында иде. Хәзер 57 нче урынга төшкәнбез.

Интеллектыбызның түбәнлеге үзен һәр өлкәдә сиздерә. Өстән алып түбәнгә кадәр бөтен җәмгыятьтә алогизм күренә, ягъни мантыйксызлык. Дума карарларын карыйсың да, шаккатасың. Мантыйк юк. Акылга түгел, теләккә таянып эш итәләр. "Мин уйлыйм", "шулай яхшы булыр иде", "проект кертәм", "закон кабул итәбез". Менә түрәләрнең мантыйгы: "ите миңа, сөяге синңа", ягъни халыкка. Ә халык мәнфәгате, ихтыяҗы буенча, закон буенча, тарих буенча, Россия менталитеты буенча ничек кирәк? Фән ничек таләп итә? Уйлап тормыйлар.

Бер мисал китерим. Россия Дәүләт Думасы үсмерләрне закон нигезендә якларга, аларга ярдәм итәргә керешә һәм закон кабул итә. Балигълыкны элеккеге кебек 18 яшьтән түгел, 14 яшьтән билгелиләр. Әйтик, балигъ булмаганны көчләгән җинаятьче 20-25 елга кадәр ирегеннән мәхрүм ителә. Балигъ булган кешегә карата кылынган җинаять өчен җәза срогы күпкә азрак. Ә Америкада бала 18 яшькә кадәр балигъ булмаган исәпләнә. Менә бу үсмерне яклау! Менә бу кеше хокукларын яклау!

Балаларның фикерләү дәрәҗәсен тиешенчә дәрәҗәдә тәрбия-ләмәсәк, без артта калган милләт булып яшәячәкбез. Безгә фикерләүнең төрле төрләрен дә өйрәтү кирәк. Һөнәри, мантыйкый, иҗади фикерләү. Моңа ирешүнең беренче чарасы - без бая телгә алган проблемалы укыту, ягъни мәсьәләне укучының үзеннән хәл иттерү.

Хәзерге заманда акылга таянмыйча бер генә ил дә икътисадый яктан алга китә алмый. АКШ, Германия, Япония кебек алдынгы илләрдә милли продуктның яртысы акыл хезмәте, яңа технологияләр нигезендә барлыкка килә. Ләкин бит за-манча технологияне нефть акчасына гына сатып алып бетереп булмый. Дөресен әйткәндә, тамакны туйдырырга да җитми әле ул җир мае биргән акча. Яңа технологияләр галим кулында, дөресрәге - аның башында. Ә фәннең үсеше туктап калды. Соңгы ун ел эчендә фәнне финанслау 30 мәртәбәгә кимеде. Ач галимнәр, квалификацияле инженерлар кая китте? Кайсы базарга, кайсы бизнеска, кайсы хакимият органнарына. Аеруча сәләтлеләре Европа илләренә яки океан артына сызды.

Фәнни потенциалга таянып, СССР беренче булып галәмгә чыкты. Ә без акыл байлыгын аяк астына салып таптадык. Бу - хакыйкать!

Эшләр җайга салына башлады, дип сөенәбез. КамАЗның елына 12 мең

машина җитештерә башлавына куанабыз. Ә бит елга 150 меңне чыгарырлык итеп салынган иде ул. Унбиш ел буе туктап торган авиация берләшмәбез быел бер самолет сатты. Анысын да лизингка, бурычка.

Чынлап та, хәзер, җитештерү беркадәр җайга салына башлагач, элеккеге квалификацияле кадрларга ихтыяҗ артты. Ләкин аларны кире кайтару кыен, бик кыен, чөнки вузларда алган белем сыек, Һөнәри мәктәпләр металл белән эш итүче белгечләрне түгел, бухгалтерлар һәм аудитлар әзерли.

Шулай итеп, интеллектны, фикерләүне үстерү - көнүзәк бурыч. Хәзер җитештерү акыл көче белән тыгыз бәйле булганга күрә, һәркем белемле булырга тиеш. Халыкара нормалар буенча халыкның уртача белем дәрәҗәсе 11 елдан югары булганда гына ул алга киткән ил санала. Америкада бу күрсәткеч 13,5 ел, Япониядә 13 ел, Россиядә 9,4 кенә ел. Матбугатта еш кына мактанабыз: Казан - вузлар шәһәре дибез. Әмма бер мең олы кешегә татарларда 177, руслар арасында 220 югары белемле кеше генә туры килә икән. Яһүдләр арасында бу күрсәткеч 527 гә җитә. 10 мең кеше башына туры килә торган студентлар саны буенча Татарстан 1999 елда Мәскәү яки Санкт-Петербургтан гына түгел, күршедәге Мари Эл Республикасыннан да артта бара иде. Фәннәр академиясендә "Җәмгыятьнең интеллектуаль потенциалы" дигән темага халыкара конференция уздырдык. Анда кабул ителгән реко-мендацияләребезнең бер өлеше генә үтәлсә дә, бераз уянган булыр идек.

Мәгарифебез алдында башка мөһим бурычлар да тора - балаларны хезмәткә өйрәтү, белемне практикада куллану күнекмәләре булдыру, укучыларның сәламәтлеген саклау. Әйтергә куркыныч, Россиядә хәзер мәктәп укучыларының 80 проценты сәламәт түгел...

Бу проблемалар киләчәк мәгарифе алдына бөтен кискенлеге белән килеп басачак. Аларны хәл итү бик кыен булыр, дип уйлыйм. Шулай да без өмет белән яшибез. Кешегә тумыштан оптимизм хисе бирелгән. Менә төзәлербез, үзгәрербез, үз-үзебезне камилләштерә, тәрбияле башларбыз, дип хыялланабыз. Коръәндә язылганны үтәп, кеше үз-үзен хәрәм эшләрдән тыяр, нәфесен чикләр, дип өметләнәбез. Ышанам, бу хыялларыбыз әле кайчан да булса бер тормышка ашар!

Әңгәмәдәш - Васил ГАРИФУЛЛИН.